ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шилангы авылы,
422577

Тел.: (84379) 32-7-48, факс: (84379) 32-7-02.

28.11.2024 г. № № 11

На № от

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Берек авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1850 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?» - Берек торак пункты чикләрендә зиратка кадәр гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча 2024 нче елның 28 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 27 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 19 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен тавыш бирде - гражданнар җыенының 18 катнашучысы; «ЮК» позициясе өчен - җыенда 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категориядән тыш, 2025 елда үзара салымны 1850 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? - Берек торак пункты чикләрендә зиратка кадәр гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылындагы гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Майоров